ГЛАВА АКБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17,
с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп урамы, 17 йорт,
Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 15 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәсенә ярашлы, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 19 ноябрендә 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан Акбаш торак пунктының КФҮ бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (тормыш иптәшләреннән, ата-аналарыннан), Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

- Акбаш торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- Акбаш торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Акбаш торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина